
# ЧИШМӘ БАШЫ

**МБМБУ "Арча шәһәренең гомуми үсеш бирү төрендәге 7 нче номерлы "Балачак" балалар бакчасы"**










| №4 | ФЕВРАЛЬ | 28.02.2025 |
| --- | --- | --- |

## 2025 ЕЛ - ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР ЕЛЫ



**“Кирәкми безгә сугыш”**

Кирәкми безгә кан кою,

Кирәкми безгә сугыш!

Безнең теләк якты, матур,

Тыныч хезмәт һәм тормыш.

Илебез зур, җиребез киң,

Хисапсыз байлык бездә!

Җир өстендә, җир астында,

Тауларда һәм диңгездә.

**Әхмәт Исхак**

“Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк”, – дип язган бөек галимебез Шиһабетдин Мәрҗани. Тарихи хәтерне саклау – киләчәк буыннар алдындагы бурычыбыз. Бу безгә буыннар бәйләнешен тирәнтен тоярга, киләчәккә ышаныч белән карарга ярдәм итә. 2025 ел Татарстанда Ватанны саклаучылар елы дип игълан ителде. Бу безнең илне саклаганнарга һәм саклаучыларга хөрмәт билгесе. Бу ел безгә Ватан сакчыларының батырлыгы белән саклanучы тарихи хәтернең һәм ил кыйммәтләренең мөһимлеген аңлата. Үткәненә хөрмәт сакламаганның – киләчәге юк. Халкыбызның анлы үткәне турындагы истәлекләрне кадерләп саклап, буыннан буынга тапшыра килү, шулар үрнәгендә илебезнең хөрмәткә лаеклы гражданнарын тәрбияләү – безнең изге бурычыбыз. Ватанны саклаучылар елы-календарь датасы гына түгел, ә милли бердәмлек һәм патриотизм символы. Бу илебезнең суверенитетын һәм иминлеген саклаган һәм яклауны дәвам иткән кешеләргә тирән рәхмәт белдерү. Бу ел безгә тарихи хәтернең мөһимлеген һәм дөньяның мәңгелек кыйммәтен искә төшерә, аны Ватанны саклаучылар үзләренең батырлыклары һәм фидакарьлекләре белән саклыйлар.

**23 февраль — Ватанны саклаучылар көне**

Хөрмәтле ир-егетләребез, сезне чын күңелдән - Ватанны саклаучылар көне белән котлыйбыз! Бүгенге бәйрәм көчле рухлылык, ир-егетләрнең кыюлык, намус һәм абруй шикелле сыйфатларга ия булуларын тагын бер кат раслый торган тантана. Туган илгә һәм үз халкыңа хезмәт итү ул, туган илен чын күңелдән сөюче гражданнарның һәрчак иң югары максаты булды һәм шулай ук булып калса иде. Хәрби хезмәткәрләрнең бүгенге көндәге буыны һәм Ватанны саклаучылар сафын тулыландырырга әзерләнүчеләр, илебезнең иминлеге, туганнары һәм якыннарының гомере өчен җаваплылык хисен онытмасыннар иде. Сезгә һәм якыннарыгызга тыныч күк йөзе, ныклы сәламәтлек, бәхет-шатлык, рухи һәм матди байлык, һәр эшегездә бары тик уңышлар гына телибез. Мөбәрак булсын бүгенге матур бәйрәмегез!!!

Бу көнне без илебез иминлеген дошманнардан батырларча саклаган, тыныч тормышта Хәрби Көчләрдә хезмәт итүче ир-егетләребезне данлыйбыз. Илебезне көчле итүче рухи кыйммәтләр: Ватанга мәхәббәт, аның мәнфәгатьләрен якларга әзер тору, дошманнардан саклау һәрвакыт үзгәрешсез кала. Һәр россияле, татарстанлы, хәрби постта булсынмы, тыныч тормышта хезмәт башкарсынмы – иң беренче чиратта үз Ватанын, туган ягын саклаучы ул.

Яшьләргә патриотик тәрбия бирүгә зур өлеш кертүче ветераннарыбызга ихлас рәхмәтләребезне җиткерәбез. Сезнең батырлыгыгыз бүген дә башкаларга үрнәк булып тора, бүгенге Ватан сакчыларының рухын ныгыта – данлы традицияләрне дәвам итү, илебез язмышы, киләчәгебез өчен зур җаваплылык аларга йөкләнә.

23 февраль һәм 8 Март-гаилә бәйрәме. Ул һәм эти мәхәббәте, кыз һәм әни мәхәббәте. Нәкъ менә гаиләдә без мәхәббәт, җаваплылык, кайгыртырга һәм хөрмәт итәргә өйрәнәбез.



Бүген безнең тәрбияләнүчеләр өлкән мәктәпкәчә яшьтәге тәрбияләнүчеләр арасында район «Строй һәм җырлар смотры» конкурсында 3 нче урынны алдылар. Ватанны саклаучылар елына багышланган. Без аларны котлыйбыз. Аларга ирешелгәннәрдә генә тукталып калмаска, һәрвакыт алга барырга, теләсә нинди үрләрне яулауларын телибез. Уңышка ирешү юлында һәрвакыт бәхетле йолдыз балкысын!





## ВАКЫЙГАЛАР ТЕЗМӘСЕ

### ТУГАН ТЕЛ КӨНЕ

Туган тел! Бу сүз һәркем өчен кадерле,газиз! Чөнки тел - тормыш чыганагы, белем чишмәсе. Аңардан да көчле, татлы, назлы, ләззәтле тел бармы икән? Тел - ананың балага иң зур бүләге. Бөтен кешегә дә үз теле якын, кадерле, хөрмәтле...

21 нче февраль - Халыкара Туган тел көне. Шул унайдан бакчабызда төрле чаралар булып узды. Бүгенге бәйрәмебез "Туган телем-иркә гөлем"исемле шигырь бәйгесе итеп оештырылды. Балалар бик матур,сәнгатьле итеп туган тел турында шигырьләр сөйләделәр.Аларның милли киемнәре, халык көйләре кулланылуы бәйрәмгә милли бизәлеш бирде. Бәйгедә катнашкан һәр баланың чыгышы жюри әгъзалары тарафыннан югары бәяләнде. Грамоталар һәм бүләкләр тапшырылды. Балаларның йөзләрендә шатлык нуры балкыды!



### ИСТӘ КАЛЫРЛЫК ОЧРАШУ

19 февральдә безнең балалар бакчасында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Алгарыш» яшьләр үзәге катнашында "Буран" КДАТУ Кар десанты" отряды булды. Кунаклар балалар өчен 23 февральгә открыткалар ясау буенча мавыктыргыч мастер-класслар һәм күңелле уеннар оештырдылар. Һәрвакыт шулай бердәм булып, аралашып яшик.

Яңа очрашуларны түземсезлек белән көтәбез .





### ШАШКА ХАНЫМДА КУНАКТА

28 нче февраль көнне без мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр арасында "шашка турниры"район конкурсында катнаштык. Безнең балалар бакчасыннан Һадиев Хәким, Вәлиева Эльвина катнашты. Дулкынлануны җиңеп, һәр катнашучы җиңүгә омтылды. Уеннар җылы, иркен шартларда үтте. Уен тәмамланганнан соң хөкемдарлар нәтиҗәләр чыгардылар һәм җиңүчеләргә лаеклы бүләкләр тапшырдылар! Кызлар арасында Вәлиева Эльвина өченче урынны алды. Ярышлар йомгаклары буенча беренче урынны безнең команда алды. Афәрин, балалар! Барлык катнашучыларга да рәхмәт. Җиңүчеләрне һәм призерларны котлыйбыз!





### СӘЛАМӘТ ТӘНДӘ-СӘЛАМӘТ АКЫЛ

19 нчы февраль көнне безнең коллегаларыбыз профсоюз оештырган чаңгы ярышында катнашып кайттылар.



### МУСА ҖӘЛИЛ – БӨЕК ШАГЫЙРЬ

Муса Җәлил - олылар һәм балалар өчен бик күп әсәрләр иҗат иткән онытылмаслык бөек шагыйрь. 15 февраль көнне Герой-шагыйрьнең тууына 119 ел тулды. Шул уңайдан безнең балалар бакчасында “Муса абый-балаларның якын дусты” исемле шагыйрьнең иҗатына күзәтү оештырылды. Балалар Муса Җәлилнең балачагы турында хикәяләрне бик кызыксынып тыңладылар,шигырьләрен яттан сөйләделәр,кисмә рәсемнәрне дөрес итеп төзеделәр.

Туган халкы көрәшче шагыйребезне беркайчан да онытмас. Герой-шагыйребезгә булган мәхәббәтебез сүнмәсен, аның якты истәлеге күңелләрдә мәңге саклансын.





## ӘЙДӘГЕЗ УЙНЫЙБЫЗ

**“Алдыр чишмә тамчылый”**

Балалар, икегә бүленеп, бер-берсеннән 20—30 метр ераклыкта тезелеп басалар. Уйнаучылар бер-берсе белән кулга-кул тотынышалар. Беренче яктагылар икенче яктагыларга кычкырып такмаклыйлар:

Алдыр чишмә тамчылый,

Гөлдер чишмә тамчылый,

Ал кирәк, гөл кирәк,

Бездән сезгә кем кирәк?

Каршы яктагылар җавап бирәләр:

Алдыр чишмә тамчылый,

Гөлдер чишмә тамчылый,

Ал да кирәк, гөл дә кирәк,

Роза матур кыз кирәк.

Исеме чыккан уенчы каршы якның сафын йөгереп барып өзеп чыгарга тырыша. Өзә алса, бер уенчыны ияртеп, үз ягына алып кайта. Өзә алмаса, шул якта кала. Уен шул тәртиптә бер якта уенчылар беткәнче дәвам итә.

## Патриотик тәрбия

Туган тел – туган җир, Туган ил төшенчәләренең төп мәгънәсен бала аңына җиткерүче иң мөһим чара. Балаларга патриотик тәрбия бирү туган телдән башка мөмкин түгел. Баланың аңы үсү, белеме арту, чынбарлыкны танып-белүе һәм чын кеше булып тәрбияләнүе аның туган телен – ана телен белүенә бәйле.
Миллләтебезгә карата олы ихтирам хисләре тәрбияләгәндә, татар халкының милли мирасыннан файдалануга җитди игътибар ителергә тиеш, шунда гына мәктәпкәчә яшьтәге балаларның туган телне яхшы үзләштерүләренә, аны ана теле итеп кабул итүләренә ирешергә мөмкин.
Патриотик тәрбия бирү төшенчәсе киң мәгънәне аңлата, ягъни ул бала күңелендә Туган илнең табигатенә, туган йортына, туган авылына яки шәһәренә, халкының тарихына, аның мәдәниятенә мәхәббәт уятудан гыйбәрәт.
Әхлакый-патриотик тәрбиянең кирәкле шарты булып әти-әниләр белән үзара тыгыз элемтә тора. Үз гаиләсенең тарихына кагылу балада көчле эмоцияләр барлыкка китерә. “Сезнең гаиләдә һәм сезнең кул астында булачак гражданин үсә… Илдә нәрсә генә булса да, сезнең күңелегез һәм сезнең фикерегез аша ул балаларга барып ирешергә тиеш”, – дип яза күренекле рус педагогы А.С.Макаренко. Укыту-тәрбия бирү процессында патриотик тәрбия бирү бакчада мөһим урын алып тора. Балаларга туган якны өйрәнү почмагы моның ачык мисалы.
Балаларда милли хисләрне тәрбияләү эше аларга халык авыз иҗатын өйрәтү, татар балалар фольклорына мөрәҗәгать итү белән дәвам иттерелә. Балалар белән кече яшьтән үк бишек җырлары тыңлыйбыз, көйләп курчакларны йоклатабыз, төрле чәбәкәй уеннары уйныйбыз, санамышлар, тизәйткечләр, бармак уеннары өйрәнәбез. Рәсем ясау, әвәләү эшчәнлекләрендә милли җырлар тыңлап, алган хисләребезне рәсемдә чагылдырабыз, милли бизәкләрне кулланып төрле композицияләрне кисеп ябыштырып эшлибез, түбәтәй, калфак , алъяпкыч, читекләр бизибез.

## ТӘМЛЕ БУЛСЫН!

**1 таба гөбәдия өчен кирәк булачак ризыклар**

**Камыр:**
* 1 стакан сөт;
* 5 аш кашыгы эретелгән атланмай;
* 1 аш кашыгы үсемлек мае;
* 2 аш кашыгы майонез;
* чеметеп кенә тоз;
* 1 бал кашыгы шикәр комы;
* 1 бал кашыгы коры чүпрә (кашык өслеге белән тигез генә булсын);
* кулдан төшеп бетәрлек итеп басарлык күләмдә он (чама белән 3 стакан). Шулай да камыр каты булмасын.

**Эчлек:**
* 1 стакан дөге;
* 1,5 стакан йөзем;
* 8 йомырка (безнең йомырка вак, шуңа күбрәк), эре булса, 5 данә;
* 2 пачка май (шуның 5 аш кашыгы камырга тотыла, 1 аш кашыгы май валчык ясарга калдырыла);
* 1 стакан тулыр-тулмас шикәр комы;
* йомырка өстенә сибәр өчен чеметеп кенә тоз;
* 250-300 г корт (табага карап алына).

**Эш барышы:**
1 стакан сөтне җылытабыз, аз гына тоз, шикәр комы, үсемлек мае, майонез, сыер мае, чүпрәне салып, камыр басабыз. Камырны сәгать, сәгать ярым күпертәбез.

**Эчлек ясау:**
кәстрүлгә су салып (дөгедән 3 тапкырга күбрәк), кайнатып чыгарабыз, тәменчә генә тоз салып, дөгене бүрттереп алабыз. Суга 1 аш кашыгы үсемлек мае салсаң, дөгене соңыннан юасы да булмый, тишекле чүмечкә салып, суытасы гына була. Яхшылап юылган йөземне дөге белән болгатабыз. Камырны куна тактасына төшереп, ике өлешкә бүләбез. Бер өлеше шактый зур, анысы – төбенә, берсе ярты уч кадәр генә, анысы – капкачына. Камырны уклау белән тәгәрәтеп җәябез.
Табаны үсемлек мае белән майлап (туңмай да ярый, ул табаны бозмый), аскы якка дигән камырны җәеп салабыз. Камыр табаны тулысынча каплый, таба читеннән асылынып тормый.
Камыр өстенә аз гына шикәр комы сибеп җибәрәбез, аннары корт җәябез, корт өстенә дә бер уч тирәсе шикәр комы сибелә. Аннары йөземле дөге салына. Дөге өстенә дә шикәр комы сибелә, бүлмә температурасында йомшарган май тезеп чыгыла. Дөге өстенә эре угычтан уылган йомырка салып, чеметеп кенә вак тоз сибәбелә.
Капкачка дигән камырны җәеп, гөбәдия өстенә каплыйбыз, кырыйларын чеметеп ябыштырабыз.
1 аш кашыгы майга 2 аш кашыгы шикәр комы, 3 аш кашыгы онны салып, уч төбе белән уабыз.
Валчыкны гөбәдия өстенә сибәбез дә, гөбәдияне күпертеп тә тормыйча, шунда ук кызу мичкә тыгабыз. 250 градуслы мичтә 30-40 минут пешерәбез. Өсте кызаруга, әзер була.

